ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЫНДЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

2023 ел, 12 май №7

Хайваннарны хуҗалардан башка кире кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Югары Ындырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының авыл җирлеге башкарма комитетына таянып, карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Югары Ындырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

ФАП территориясе;
мәктәп территориясе;
балалар бакчасы территориясе;
парклар, скверлар территориясе;
балалар уен мәйданчыклары территориясе.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Югары Ындырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына йорт хуҗаларыннан башка гына терлекләрне элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләп куярга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Югары Ындырчы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ындырчы авыл
җирлеге Башлыгы Ф.М.Гафиятуллин